**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КРАСНОСЕЛЬСКИЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
422700, ТР Биектау районы, Биектау тимер юл станциясе поселогы, Совет урамы, 13

**ИСПОНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КРАСНОСЕЛЬСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
422700, Высокогорский район РТ, п. ж/д ст. Высокая Гора, ул. Советская, 13

тел./факс 8(84365) 2-35-85, 2-35-82,e-mail: Ksel.Vsg@tatar.ru

**КАРАР** **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**17 апрель 2015 ел** **№ 144**

**Табигать янгыннарын кисәтү һәм бетерү буенча эшне оештыру турында.**

2014 нче елның апреленә, маена тискәре метеорологик фараз белән бәйле рәвештә и «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 нче елның 6 нчы октябрендәге № 131–ФЗ Федераль законга, 1994 нче елның 21 нче декабрендәге «Янгын куркынычсызлыгы турында» 69-ФЗ номерлы Федераль зонның 10, 19, 25, 26, 34, 37 нче статьяларына, «Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» Федераль законның 2 нче бүлегенең 2 нче статьясына таянып, Красносельский авыл җирлеге территориясендә табигый янгыннарны кисәтү һәм бетерү буенча эшне оештыру максатыннан

**КАРАР БИРӘМ:**

1. Табигый янгыннарны кисәтү һәм бетерү эшләрен оештырган өчен Красносельский авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесен җаваплы зат итеп билгеләргә.

2. Табигый янгыннарны кисәтү һәм бетерү эшләрен оештыру өчен җаваплы затка:

2.1. 2015 нче елның 30 нчы апреленә кадәр авыл җирлеге территориясендә минераллаштырылган полосаны чистартырга;

2.2. 2015 нче елның 30 нчы апреленә кадәр авыл җирлегендә планлы яндырулар үткәрүне оештырырга;

2.3. 1 нче кушымта нигезендә, янгын сүндерүгә җәлеп ителгән көчләрне һәм чараларны билгеләргә;

2.4. 2015 нче елның 10 нчы маена кадәр Красносельский авыл җирлеге территориясен, барлык йорт территорияләрен һәм алар янәшәсендәге территорияләрне ягулык калдыкларыннан (чүп-чардан, коры үләннән, коелган яфраклардан) чистартуны оештырырга.;

2.5. Янгын сүндерү максатларында җирлек территориясендә урнашкан тышкы су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алу өчен шартлар тудыру:

- үзәк су кудыргыч буенча җаваплы итеп «Биектау коммуналь челтәрләре

ААЖ җитәкчесе билгеләнде.

2.6. Янгын турында халыкка һәм ГПС бүлекчәләренә хәбәр итү ысулларын күрсәтеп хәбәр итүне оештыру буенча чаралар күрергә:

- сирена

-кыңгырау

- кәрәзле элемтә;

2.7. Гомуми кулланылыштагы территорияләрне беренчел янгын сүндерү чаралары һәм янгынга каршы инвентарь белән җиһазлау.

2.8. Табигый янгын чыгу куркынычы янаган очракта, торак пунктка янгынны локальләштерү һәм кешеләрне һәм мөлкәтне коткару буенча ГПС бүлекчәләре килгәнче чаралар күрергә кирәк.

2.9. Эвакуация чараларын үткәрү өчен халыкны эвакуацияләү маршрутын эшләргә, 2 нче кушымта нигезендә вакытлыча урнаштыру пунктын, Транспорт һәм кешеләр санын билгеләргә.

2.10. 2015 нче елның 1 нче маена кадәр 3 нче кушымта нигезендә күзәтү стационар постын кую урыннарын билгеләргә.

2.11. Оператив штабның эш урынын оештырырга, оператив төркем гамәлләренә идарә итәргә һәм «Татарстан Республикасы буенча Россия ГТХМ ЦУКСЫ» ДУДА (Красносельский авыл җирлеге башкарма комитеты) мәгълүматны билгеләнгән вакытка тапшырырга.

2.12. Авыл янында башлангыч стадияләрдә ачыкланган янгыннарны бетерү өчен автотранспортта 3 кешедән торган оператив төркем төзергә.

2.13. 2015 нче елның 1 нче маена кадәр торак пунктны Урман һәм башка ландшафт янгыннарыннан саклау өчен көчләрнең һәм чараларның әзерлеген тикшерү.

3. Табигать янгыннарын кисәтү һәм бетерү буенча чараларны финанслауны «Биектау муниципаль районы» бюджеты хисабына тормышка ашырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Красносельский авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе Р.А. Зайнуллин